# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Көрәш-Бүләк торак
пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**19.11.2022 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыенының йомгак беркетмәсе төзелде: "Сез 2023 елда үзара салым кертүгә Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 500 (биш йөз) сум күләмендә акча кертүгә килешәсезме?:

- Көрәш-Бүләк торак пунктында авыл клубы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)".

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 110 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында 56 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 56 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында халык җыены узды һәм халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2."Сез 2023 елда үзара салым кертүгә Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 500 (биш йөз) сум күләмендә акча кертүгә килешәсезме?:

- Көрәш-Бүләк торак пунктында авыл клубы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)" - соравын кабул ителде дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 5 көн эчендә Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://jutaza.tatarstan.ru,түбәндәге адрес буенча хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы Әхмәтов Ф.В.